ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2023 елда Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматы хакында

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Ф.С. Габделганиевның (алга таба – Вәкаләтле вәкил) 2023 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Вәкаләтле вәкилнең 2023 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Вәкаләтле вәкилнең 2023 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматындагы тәкъдимнәрне республика башкарма хакимияте органнары белән берлектә гамәлгә ашыру чараларын күрергә.

2.2. Түбәндәгеләр буенча эшне дәвам итәргә:

республикада кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аларның продукциясен (хезмәт күрсәтүләрен) чыгаруда һәм аны сату базарларын киңәйтүдә, шул исәптән Республика маркетинг үзәге аша, ярдәм итү;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларының республика һәм федераль ярдәм чаралары күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итү активлыгын арттыру;

кече һәм урта бизнесны үстерү белән идарә итү системасына цифрлы технологияләр кертү;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларын, республиканың цифрлы икътисадын үстерүнең максатларын һәм бурычларын исәпкә алып, квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү.

3. Вәкаләтле вәкилгә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Түбәндәгеләр буенча актив һәм максатчан эш алып баруны дәвам итәргә:

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына артык административ басымны киметү, аларга нигезсез тикшерүләр үткәрү фактларын бетерү;

Татарстан Республикасында эшлекле һәм инвестицион мохитне яхшыртуга ярдәм итү;

кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә федераль һәм республика законнарын камилләштерү;

Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актлары проектларына җайга салу йогынтысын бәяләү процедураларында катнашу;

Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

дәүләт хакимияте органнары, эшкуарларның иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлекне камилләштерү;

Татарстан Республикасы эшкуарлык бергәлегенә республика территориясендә гамәлдә булган кече һәм урта эшкуарлыкка дәүләт ярдәме чаралары турында хәбәр итү.

3.2. Эшкуарлар хокукларын яклау институтын камилләштерү максатларында Россия Федерациясе субъектларында эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилләр белән актив хезмәттәшлек итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына закон проектларын әзерләгәндә һәм Вәкаләтле вәкил эшчәнлеге өлкәсендә парламент контролен гамәлгә ашырганда аның белән хезмәттәшлекне көчәйтергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2392-VI ДС